ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРМАШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.114 , с.Сармаш-Баш,
Заинский район, 423532 тел./факс
8(85558) 3-90-30, e-mail:
Sbash.Zai@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРМАШ-БАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк урамы, 114 нче йорт,
Сармаш-Баш авылы, Зәй районы,
423532 тел./факс 8(85558) 3-90-30,
e-mail: Sbash.Zai@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
от 09.02.2021 № 2

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» №73 31.01.2020 ел Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2021 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6424,98 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2020 елның 31 декабрендәге 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.М.Фәсхетдинов**

Зәй муниципаль районы
Сармаш-Баш авыл җирлеге
башкарма комитетының
«09» февраль 2021 ел
02 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 01 февраленнән
Сармаш-Баш авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 443,73 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1044,51 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 936,74 |
| Барысы | 6424,98 |

Зәй муниципаль районы
Сармаш-Баш авыл җирлеге
башкарма комитетының
«09» февраль 2021 ел
02 номерлы карарына
2 нче кушымта

Сармаш-Баш авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 670,08 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1823,71 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1019,54 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2911,65 |
| Барысы | 6 424,98 |